РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Рыбно-Слободский
муниципальный район
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Анатышского
сельского поселения
Рыбно-Слободского
муниципального района
Клубная ул., д. 17
село Анатыш , 422643

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Балык Бистәсе
Муниципаль районы
Анатыш
авыл җирлеге
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Клуб урамы, 17 нче йорт,
Анатыш авылы , 422643

Тел.: (8-843-61) 23-285, факс: (8-843-61) 23-285; электронный адрес: Anat.Rs@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01. 2021ел. с.Анатыш №2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында .

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пунктын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Пенсия фондының 2021 елның 13 гыйнварындагы “2021 елның 1 февраленнән Россия Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган индексацияләү турында”гы СЧ-25-24/270 номерлы хатына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2 нче кушымталар нигезендә 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында” 2020 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карарын 2021 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында:

- Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Анатыш авылы, Клуб урамы, 17 йорт;

-Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шиланка авылы, Набережная урамы, 1 йорт;

- Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырылган: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Анатыш авыл җирлеге башлыгы К.К.Җамалиев

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Анатыш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
25.01.2021 елның 2 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлегендә**
**2021 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең**
**Гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган**
**Хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәт күрсәтүнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табутһәм башка кирәк- яракларны бирү һәм китерү | 1966 |
| 3. Мәетне (гәүдә калдыкларын) зиратка (крематорийга) илтү | 975 |
| 4. Җирләү (кабер казу ḥәм күмү), кремацияләнгән мәет калдыклары | 3483,98 |
| Барлыгы: | 6424,98 |

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Анатыш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
25.01.2021 елның 2 номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирләү буенча Анатыш авыл җирлегендә хатыны, якын туганнары, башка туганнары яисә үлгән затның законлы вәкиле булмаганда яисә җирләүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә алган бүтән зат булмаганда күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү, киендерү | 542 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яракларны бирү һәм китерү | 1424 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәд калдыкларын) зиратка илтү | 975 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3483,98 |
| Барлыгы | 6424,98 |